Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл Советы

КАРАРЫ

26 снтябрь 2023 ел № 73

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2013 елның 25 ноябрендәге 79 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге икенче өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлеге Уставының 29 статьясы нигезендә,

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 79 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 110 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 132 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 89 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 6 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктны түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 номерлы карары нигезендә аккредитацияләнгән кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм инфраструктурасы субъектлары реестрына кертелгән сәнәгать (индустриаль, агросәнәгать) паркы һәм сәнәгать технопаркы (алга таба - сәнәгать паркы) биләгән җир кишәрлекләре, 1 елга;

1.2. 5 пунктның алтынчы абзацын җиденче абзац дип санарга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталына» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Колшәрип авыл Советы башлыгына йөкләргә.

Колшәрип авыл
җирлеге башлыгы А.Ф. Кәшәфетдинов